КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 гыйнвар г.Казань № 52

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 июль, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы; 2017 ел, 18 май, 291 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 278 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1156 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә:

4.2.1. Түбәндәгеләрне (җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналардан тыш) билгели:

тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларның иң чик (мини-

маль һәм (яки) максималь) дәрәҗәләре кысаларында 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр энергиясен (куәтен) җитештерүнең билгеләнгән генерацияләү куәте белән җылылык энергиясе чыганаклары ярдәмендә электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифны;

тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларның иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләре кысаларында җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифны, шулай ук җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифны;

җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җылылык энергиясен (куәтен) кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык йөрткечкә тарифны;

җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган кайнар суга тарифны;

җылылык энергиясен, җылылык йөрткечне тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифны;

җылылык энергиясен кулланмаганда резерв җылылык куәтен тәэмин итү буенча хезмәт күрсәткән өчен түләүне;

җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган (технологик тоташтырган) өчен түләүне.

4.2.2. Җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналарда түбәндәгеләрне билгели:

җылылык энергиясенә (куәтенә) бәянең иң чик дәрәҗәсен;

җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып, җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешмалар тарафыннан кулланучыларга һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җибәрелә торган су рәвешендәге җылылык йөрткечкә тарифны (әлеге җылылык йөрткеч белән тәэмин итү җылылык энергиясе чыганагына милек хокукында яки башка законлы нигездә ия булган җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык куллану җайланмалары әлеге җылылык энергиясе чыганагы белән турыдан-туры яки җылылык челтәре аша технологик тоташтырылган кулланучыга карата (әлеге чыганакка әлеге җылылык белән тәэмин итүче оешма яки әлеге кулланучы милек хокукында яки башка законлы нигездә ия булганда) гамәлгә ашырылган очрактан тыш), әгәр дә мондый җылылык куллану җайланмалары һәм мондый җылылык челтәре җылылык белән тәэмин итү системасы белән башка төрле технологик тоташтырылмаган һәм әлеге кулланучының җылылык челтәрләренә башка кулланучыларның җылылык куллану җайланмалары тоташтырылмаган булса;

җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып, җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешмалар тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган, җылылык йөрткеч өчен компонентны һәм җылылык энергиясе өчен компонентны файдаланып, ике компонентлы тариф формуласы рәвешендә билгеләнгән кайнар суга тарифны;

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль законның 10 статьясындагы $12^1 – 12^4$ өлешләрдә күрсәтелгән очракларда, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә товарларга, хезмәт күрсәтүләргә тарифны;

тоташтыру (технологик тоташтыру) турында шартнамә төзегән яклар тарафыннан җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган (технологик тоташтырган) өчен түләү күләме турындагы килешү төзелмәгән очракта кулланыла торган җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган (технологик тоташтырган) өчен түләүне.

4.2.3. Җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналарда түбәндәгеләрне индексацияләүне гамәлгә ашыра:

җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешма һәм җылылык челтәре оешмасы арасында җылылык энергиясен, җылылык йөрткечне тапшыру буенча хезмәт күрсәтү бәясенә карата фикерләр каршылыгы барлыкка килгән очракларда, җылылык энергиясен, җылылык йөрткечне тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләр өчен исәп-хисапларны гамәлгә ашыру максатларында, тиешле җылылык челтәре оешмасы өчен билгеләнгән һәм җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналарда күчү чоры тәмамланган көнгә гамәлдә булган җылылык энергиясен, җылылык йөрткечне тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифны;

җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешма һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон нигезендә әлеге җылылык энергиясе чыганакларын эксплуатацияләүдән чыгаруны туктату турында карар кабул ителгән җылылык энергиясе чыганаклары милекчесе яки законлы хуҗасы арасында җылылык энергиясе (куәте) бәясенә карата фикерләр каршылыгы килеп чыккан очракларда, җитештерелгән җылылык энергиясе (куәте) өчен исәп-хисапларны гамәлгә ашыру максатларында, тиешле җылылык челтәре оешмасы өчен билгеләнгән һәм җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналарда күчү чоры тәмамланган көнгә гамәлдә булган ике ставкалы тарифның җылылык энергиясе өчен ставканы;

җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешма һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон нигезендә әлеге җылылык энергиясе чыганакларын эксплуатацияләүдән чыгаруны туктату турында карар кабул ителгән җылылык энергиясе чыганаклары милекчесе яки законлы хуҗасы арасында җылылык энергиясе (куәте) бәясенә карата фикерләр каршылыгы килеп чыккан очракларда, җитештерелгән җылылык энергиясе (куәте) өчен исәп-хисапларны гамәлгә ашыру максатларында, җылылык энергиясе чыганагыннан (чыганакларыннан) пар һәм (яки) су рәвешендә җибәрелә торган җылылык энергиясенең бер гигакалориясенә кертелгән, тиешле җылылык челтәре оешмасы өчен билгеләнгән һәм җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган

зоналарда көчү чоры тәмамланган көнгә гамәлдә булган бер ставкалы тарифта исәпкә алынган ягулык өчен чыгымнар күләмен.

4.2.4. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларга арттыру коэффициентларын билгели.

4.2.5. Россия Федерациясенең җылылык белән тәэмин итү турындагы законнары нигезендә җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларны җайга салуны өлешчә яки тулысынча гамәлдән чыгару турында, аны гамәлдән чыгарганнан соң җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салуны кертү турында карарлар кабул итә.

4.2.6. Җирле үзидарә органының Татарстан Республикасы законы нигезендә тапшырылган вәкаләтләрен үтәү йөзеннән «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль законга таянып кабул ителгән, әмма Россия Федерациясе законнарына каршы килә торган яки бирелгән компетенциясеннән арттырып файдаланып кабул ителгән карарларын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән тәртиптә гамәлдән чыгара.

4.2.7. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын җирле үзидарә органнары белән килештереп раслый.

4.2.8. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу ысулларын сайлый.

4.2.9. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чорына билгеләнә торган бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуның озак вакытлы параметрларын билгели.

4.2.10. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.

4.2.11. «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон белән күздә тотылган очракта, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуның конкурс документларына кертелә торган озак вакытлы параметрлары мәгънәләрен килештерүне гамәлгә ашыра.

4.2.12. Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары белән күздә тотылган очракларда, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуның озак вакытлы параметрлары мәгънәләрен (эшчәнлекне җайга салуның (концессионерның) озак вакытлы параметрларын) килештерүне, шулай ук аларга үзгәрешләр кертүне алдан килештерүне гамәлгә ашыра.

4.2.13. Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон нигезендә конкурс оештыручының яки концедентның җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу ысулын сайлап алу турындагы карарын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килештерүне гамәлгә ашыра.

4.2.14. Конкурс оештыручының яки концедентның соравы буенча конкурс документларына кертелә торган бәяләр, күләмнәр, мәгънәләр һәм параметрлар

турындагы мәгълүматны Россия Федерациясенең җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә бирә.

4.2.15. «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, бәяләрне (тарифларны) билгеләү, аларга үзгәреш һәм төзәтмәләр керткән вакытта гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән күздә тотылган кагыйдәләр буенча аренда шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә арендага алучы тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) билгеләүне, аларга үзгәреш һәм төзәтмәләр кертүне килештерә.

4.2.16. Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары белән билгеләнгән очракларда, бәяләрне (тарифларны) билгеләү, аларга үзгәреш һәм төзәтмәләр керткән вакытта гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән күздә тотылган кагыйдәләр буенча концессия килешүенең гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр концессионер тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) билгеләүне, аларга үзгәреш һәм төзәтмәләр кертүне килештерә.

4.2.17. Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык челтәре оешмаларына һәм кулланучыларга мәгълүмат бирү максатларында, җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналарга кертеп каралмаган җирлекләрдә, шәһәр округларында җылылык белән тәэмин итүнең бәясе билгеләнеп куелган зоналарда җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен билгеләү кагыйдәләре (җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен индексацияләү кагыйдәләрен кертеп), «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган су кайнату казаннары һәм җылылык челтәрләре эшләвенең техник-икътисадый параметрлары нигезендә билгеләнгән җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләр дәрәҗәсен исәпләп чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыруны тәэмин итә.

4.2.18. Тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына тарифларны билгеләү, куллану һәм аларга үзгәртеш кертү, шул исәптән «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон нигезендә җайга салына торган җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәләрен билгеләү һәм аларга үзгәреш кертү мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм кирәкле материалларны «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон, шулай ук тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән расланган җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә

мәгълүмат бирү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракларда, форматта һәм вакытларда кертә.

4.6 нчы пунктта:

4.6.1 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.1. Федераль законнар белән билгеләнгән очракларда, автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифларны һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифларны билгели.»;

4.6.3 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3. Шәһәр элемтәсендә (автомобиль транспортыннан һәм шәһәр җир өсте электр транспортыннан тыш) һәм шәһәр яны элемтәсендә (тимер юл транспортыннан, автомобиль транспортыннан һәм шәһәр җир өсте электр транспортыннан тыш) гомуми файдаланудагы барлык транспорт төрләре белән пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифларны һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифларны билгели.»;

6.5 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия эшчәнлеге тәртибе (утырышлар үткәрү тәртибен дә кертеп) рәис тарафыннан билгеләнә.»;

дүртенче һәм бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин